Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз беренче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
карары

26 март, 2020 ел № 248

2019 елда Татарстан Республикасында кеше һәм
граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында

Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Питрәч муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе «2019 елда Татарстан Республикасында һәм Питрәч муниципаль районында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау турында» мәгълүматын тыңлаганнан соң **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. 2019 елда Татарстан Республикасында һәм Питрәч муниципаль районында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен үтәү турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Җирле үзидарә органнарына, Питрәч муниципаль районының барлык милек рәвешләрендәге учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләренә, эшендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесенең мәгълүматын исәпкә алырга, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен бозу очракларына юл куймау буенча чаралар күрергә, халыкны хокукый яктан агарту чараларын активрак үткәрергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов